ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме икенче утырышы каравына кертелә торган мәсьәләләр турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Бишенче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының егерме икенче утырышы каравына түбәндәге мәсьәләләрне кертергә:

1. Татарстан Республикасы җәмәгать судьясын сайлау турында.
2. Павлова Ольга Ивановнаның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылуы турында.
3. “2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында” 282-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. “2017 елга, 2018 һәм 2019 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында” 283-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
5. “Татарстан Республикасында азык-төлек продукциясенең сыйфатын һәм куркынычсызлыгын тәэмин итүнең аерым чаралары турында” 253-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (III укылыш).
6. “Татарстан Республикасында кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 258-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (II укылыш).
7. “Татарстан Республикасы Түбән Кама районы Алан авылының гамәлдә булуын юкка чыгару һәм “Түбән Кама муниципаль районы” муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 281-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

8. “Татарстан Республикасы Экология кодексының 8 статьясына үзгәреш кертү турында” 279-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

9. “Татарстан Республикасында урманнардан файдалану турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 278-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

10. “Татарстан Республикасы Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында” 280-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).

11. “Мәгариф турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 274-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

12. “Китапханәләр һәм китапханә эше турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 275-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

13. “Вөҗдан иреге турында һәм дини берләшмәләр турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында” 276-5 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

14. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында.

15. Татарстан Республикасының Граждан хәле актларын теркәү органнары хезмәткәре көнен билгеләү турында.

16. “Җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр турында” Федераль законның 51 һәм 53 статьяларына һәм “Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында” Татарстан Республикасы Дәүләт Советының 2016 елның 28 июнендәге 1335-V ДС номерлы карарына үзгәреш кертү хакында.

17. “Россия Федерациясе Җинаять-процессуаль кодексының 447 һәм 448 статьяларына үзгәрешләр кертү турында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

18. “Бакчачылык, яшелчәчелек һәм дача хуҗалыгы турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 1160742-6 номерлы федераль закон проекты турында.

19. “Җир асты байлыклары турында” Россия Федерациясе Законының $2^{1}$ статьясына үзгәреш кертү хакында” 1165647-6 номерлы федераль закон проекты турында (федераль әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләре исемлеген киңәйтү өлешендә).

20. “Дәүләт яисә муниципаль милектәге һәм Ерак Көнчыгыш федераль округы составына керә торган Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә урнашкан җир кишәрлекләрен гражданнарга бирү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” 1177357-6 номерлы федераль закон проекты турында (җир кишәрлекләре бирү тәртибен һәм шартларын төгәлләштерү өлешендә).

21. “Россия Федерациясе Урман кодексының 17 статьясына үзгәреш кертү турында” федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Архангельск өлкә депутатлар Собраниесенең закон чыгару инициативасы хакында.

22. “Ябык административ-территориаль берәмлек турында” Россия Федерациясе Законына һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 1148859-6 номерлы федераль закон проекты турында (ябык административ-территориаль берәмлекне үзгәртеп кору, бетерү һәм аның чикләрен үзгәртү тәртибен төгәлләштерү өлешендә).

23. “Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 1112847-6 номерлы федераль закон проекты хакында (банкротлыкның аерым процедураларын гамәлгә ашыру тәртибен үзгәртү һәм дәүләт сатып алуларында катнашучылар өчен өстәмә чикләүләр билгеләү өлешендә).

24. Хөкүмәт сәгате: “Татарстан Республикасында музейлар һәм музей эше турында”.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2016 елның 26 октябре
№ 1421-V ДС